БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 11 2024 ел № 281

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдә булган законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 07 маендагы 183 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы Нигезләмәгә, 5 пунктның өченче абзацындагы җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Кунакханәдә яшәгәндә күрсәтелгән яшәү вакыты шартнамә, касса чегы яисә катгый хисап бланкында рәсмиләштерелгән, командировкалау урыны буенча кунакханә хезмәтләре күрсәтүне раслый торган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 ноябрендәге «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 1853 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрендә каралган белешмәләрне үз эченә алган документ белән раслана.».

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына билгеләнгән тәртиптә кертелгән үзгәрешләр нигезендә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение җитәкчеләренә үз хезмәткәрләрен кертелгән үзгәрешләр белән таныштырырга.

5. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение хезмәткәрләренә командировка чыгымнарын каплаганда кертелгән үзгәрешләргә таянырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов